**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ**
**“АЕРЫМ ПРЕДМЕТЛАР ТИРӘНТЕН ӨЙРӘНЕЛӘ ТОРГАН**
**2НЧЕ АЛЕКСЕЕВСК УРТА ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ МӘКТӘБЕ”**
**МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ ГОМУМИ БЕЛЕМ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ**

| **“КАРАЛДЫ”** | **“КИЛЕШЕНДЕ”** | **“РАСЛАНДЫ”** |
|---|---|---|
| МБ җитәкчесе | «2 нче Алексеевск УГББМ” МБГБУ директор урынбасары | «2 нче Алексеевск УГББМ” МБГБУ директоры |
| ________Замалиева И.Х | ________Ягудина Л.Р. | ________Диплянина Л.Н. |
| МБ утырышы беркетмәсе №_1_ _25_август 2016 ел | _27_ август 2016 ел | _239_ номерлы боерыгы ___ август 2016 ел |

**Татар теле һәм әдәбияты укытучысы**
**Замалиева Илсөяр Хәнифовнаның**
**1 “В” сыйныфы өчен әдәби укудан**
**эш программасы**

Педагогик совет утырышында каралды
_1_ номерлы беркетмә
_31_ август 2016 ел

2016-2017 уку елы

**I.Укыту предметын үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре**
**Сыйныф :** 1В сыйныфы (татар төркеме)

**Сәгать саны:** 33 сәгать, атнага 1 сәгать.

”Рус мәктәпләрендә укучы татар балаларына ана теле һәм әдәбият укыту программалары”

1-11 нче сыйныфлар. Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгы, Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2011ел.

Дәреслек: Ф.Ш.Гарифуллина, И.Х.Мияссарова .Әдәби уку: Рус телендә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбенең 1 нче сыйныфы өчен дәреслек( татар телендә сөйләшүче балалар өчен) . – Казан: Мәгариф-Вакыт, 2012.

Эш программасы түбәндәге документларга нигезләнеп төзелде:

1.Программа: “Рус мәктәпләрендә укучы татар балаларына ана теле һәм әдәбият укыту программалары” (Ф.Ф.Харисов, Ч.М. Харисова,В.А. Гарипова, Р.Р. Җамалетдинов, Р.Ф.Җамалетдинова. Казан. “Мәгариф” нәшрияты, 2010)

2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем учреждениясе “Аерым предметларны тирәнтен өйрәнүче Алексеевск 2 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе”нең төп гомуми белем бирү баскычында гомуми башлангыч белем бирү программасы.
3. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем учреждениясе “Аерым предметларны тирәнтен өйрәнүче Алексеевск 2 нче урта гомуми белем мәктәбе”нең 2016-2017 уку елына укыту планы (№1 педсовет протоколы, 31 август 2016 ел)

**II.Укыту предметының эчтәлеге**

.

1 нче сыйныфта “Телдән әзерлек чоры”нда, татар әдәби тел нормаларына өйрәтү күздә тотыла. Алар буенча әңгәмәләр оештыру – бик җаваплы эш, чөнки балаларның күбесе беренче тапкыр тематик принцип нигезендә системалы рәвештә татарча сөйләшү күнекмәләре булдыра башлый. Шуңа күрә эшнең ни дәрәҗәдә нәтиҗәле булачагы әйтелгән этапның уңышлы үтүенә бәйле.

“Телдән әзерлек чоры” өчен сүзләр үрнәк буларак тәгъдим ителә. Кайсы дәрестә ничә һәм нинди сүз өйрәнүне укытучы үзе хәл итә, чөнки татар теле – рус җирлегендә яшәсә дә, татар баласы өчен ана теле, андагы күп сүзләр укучыга таныш булырга мөмкин.

“Әлифба чоры”нда татар һәм рус телләрендә бердәй әйтелешле авазлар кергән сүзләрне дөрес әйтергә өйрәтү, алар белән иҗекләр, сүзләр, сүзтезмәләр һәм җөмләләр төзетү күз уңында тотыла. Әйтелешнең үзенчәлекләрен балаларга күрсәтүдә техник чаралардан файдалану, дәресләрдә төрле уеннар уйнау да уңай нәтиҗәләргә китерә.

Хәрефләрдән иҗекләр төзү, аннан соң иҗекләрдән – сүзләр, сүзләрдән сүзтөзмәләр төзеп уку. Сүзтезмәләрдән җөмләләр төзү күнекмәләре тәрбияләү. Сүзләрне иҗекләргә бүлү.

Эчтәлеген аңлап, кирәкле урыннарда паузалар ясап, сүз басымын дөрес куеп уку.

Әлифба чорында татар һәм рус телләрендә бердәй әйтелешле авазлар белән ([б], [п], [д],[т], [ж], [ш], [з], [с], [и], [й], [л], [м], [н], [р], [у], [ф], [ц], [щ])танышу, алар кергән сүзләрне дөрес уку.

[а],[о],[э/е],[w],[гъ],[къ],[х],[ч],[ы] авазларының әйтелеш үзенчәлекләре һәм бу авазларны язуда дөрес күрсәтү.

Татар телендәге [ә], [ө], [ү], [җ], [ң], [һ] авазлары кергән сүзләрне, сүзтезмәләрне һәм җөмләләрне дөрес уку.

"Әлифбадан соңгы чор"да "Уку һәм сөйләм үстерү", "Ятлау өчен әсәрләр", "Сөйләшү тематикасы" кебек бүлекләр бирелгән. Дәреслектә алар тематик принципта төзелгән.

Сөйләшү тематикасы үтелгән материалдан, аңа бәйле лексик-фразеологик минимумнан чыгып билгеләнде. Ул укучыларда әдәпле сөйләм формалаштыру максатын күздә тотып кертелде. Билгеле, укытучы аны сыйныф саен тирәнәйтә һәм баета барырга тиеш. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән "Рус телендә урта(тулы) гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар теле һәм әдәбиятыннан үрнәк программалар"буенча 1 нче сыйныфлар өчен әдәби укуны укытуга 64 сәгать каралган. Мәктәпнең еллык календарь укыту графигы буенча 1 нче сыйныфларда 33 атна булу сәбәпле, эш программасы белем бирү учреждениесенең 2014 -2015 елга гамәлдәге базис планы буенча атнага 1 сәгать исәбеннән 33 сәгатькә төзелә. Эш программасында, барлык өйрәнелә торган темалар сакланып, сәгатьләр санына үзгәрешләр кертелде. Бу үзгәрешләр программаның эчтәлегендә күрсәтелә. 1 нче сыйныф өчен әзерләнгән эш программасының эчтәлеген мәктәптә үзләштерелергә яки камилләштерелергә тиешле махсус белем һәм күнекмәләр тәшкил итә.

**"Әдәби уку" курсы түбәндәге максатларны һәм бурычларны күз алдында тота:**

- Кече яшьтәге мәктәп балаларын аңлап,дөрес, йөгерек һәм сәнгатьле укырга өйрәтү; төрле типтагы текстлар белән эшләүне тәэмин итүче барлык сөйләм эшчәнлеге төрләрен камилләштерү; китап укуга карата кызыксыну үстерү; китап укучының белем дәрәҗәсен формалаштыру; китап сайлау һәм мөстәкыйль китап уку тәҗрибәсе туплау;

- Әдәби әсәрләр ярдәмендә балаларда әхлак тәрбиясе булдыру;яхшылык,дуслык,дөреслек һәм җаваплылык турында күзаллау формалаштыру; күпмилләтле Россия халыклары һәм татар халкы мәдәниятенә карата кызыксыну һәм хөрмәт тәрбияләү.

**Универсаль уку күнекмәләре.**

| Шәхси универсаль уку гамәлләре. | Регулятив универсаль уку гамәлләре. | Танып-белү универсаль уку гамәлләре. | Коммуникатив универсаль уку гамәлләре. |
|---|---|---|---|
| 1.Түбәндәге кыймматләрне аңлый һәм бәяли белү: яхшылык,түземлелек, табигать, туган ил, гаилә һ.б. Үз гаиләңә, туганнарыңа, ата-анаңа хөрмәт.<br>2.Укучы ролен үзләштерү. Укуга карата кызыксыну формалаштыру.<br>3. Гомумкешелек нормалары күзлегеннән чыгып, тормыш ситуацияләрен, геройларның үз-үзләрен тотышларын бәяләү. | 1.Укытучы җитәкчелегендә эш урынын әзерләү, оештыру.<br>2.Укытучы җитәкчелегендә дәрестә, дәрестән тыш эшчәнлектә, тормыш ситуацияләрендә биремнәрне үтәү максатын билгеләү.<br>3.Укытучы җитәкчелегендә дәрестә, дәрестән тыш эшчәнлектә, тормыш ситуацияләрендә биремнәрне үтәү планын билгеләү. | 1.Китап белән эшләү: бирелгән бүлекне өйрәнгәндә формалашучы белем-күнекмәләрне билгеләү.<br>2.Укытучының гади сорауларына җавап бирү, дәреслектән тиешле мәгълүматны табу.<br>3.Геройларны, аларның гамәлләрен чагыштыру, уртак һәм аермалы якларын табу.<br>4.Укылган яки тыңланган текстның эчтәлеген сөйләү. | 1.Дәрестә һәм тормыш ситуацияләрендә диалогта катнашу.<br>2.Укытучы, сыйныфташларның сорауларына җавап бирү.<br>3.Сөйләм этикеты нормаларын үтәү: исәнләшү, хушлашу,рәхмәт белдерү;<br>4.Башкаларның сөйләмен тыңлап аңлау.<br>5. Парлап һәм күмәк эшләү. |

**Регулятив универсаль уку гамәлләрен** формалаштыру чарасы булып – продуктив уку технологиясе ; **танып-белү универсаль уку гамәлләрен** формалаштыру чарасы булып- дәреслектәге текстлар, беренчел мәгълүмат белән эшләү күнекмәләрен тәэмин итүче методик аппарат;**коммуникатив универсаль уку гамәлләрен** формалаштыру чарасы булып продуктив уку технологиясе һәм эшне парлап, кечкенә төркемнәрдә оештыру хезмәт итә.

**Предмет нәтиҗәләре:**

-укытучы, укучы укыган текстны ишетеп аңлау;
-бөтен сүзләрне аңлап, дөрес уку;
-текстны тулысынча сөйләү;
-кечкенә күләмле шигырьләрне ятлау;
-рәсем буенча телдән хикәя төзү;
-автор,текст исеме һәм текстның эчтәлеген билгеләү;
-хикәя , шигырьне аера белү.

### III. Төп уку эшчәнлеге төрләре күрсәтелгән тематик планлаштыру

| № | Дәреснең темасы | Төп эшчәнлек төрләре | Үткәрү вакыты |
|---|---|---|---|
| 1 | Р.Бәшәр “Танышу” шигыре.<br>БСҮ  Әдәпле сүзләр. | .Укытучының гади сорауларына җавап бирү, дәреслектән тиешле мәгълүмат табу. | 5.09 |
| 2 | Г. Тукай. “Әлифба”.<br>Ш..Галиев “Таяк” шигыре. | Шигырнең эчтәлеге белән танышу, әңгәмә | 12 |
| 3 | Дәрдемәнд. “Балалар, әйдә мәктәпкә!” | Сәнгатле укырга өйрәтү конкурска әзерләнү | 19 |
| 4 | Р. Вәлиева “Беренчеләр”.<br>Р.Миңнуллин “Кояш” шигыре. | Рәсем ясау сөйләү | 26.09 |
| 5 | Э. Шәрифуллина. “Күзең күргәч”.<br>Х.Халиков “ Сакчы күркә” шигыре. | Эчтәлеген аңлату схема ясау | 3.10 |
| 6 | БСҮ Туган телне өйрәнәбез.<br>Ш. Маннапов. “Ат ник көлә?”. | Шигырнең төп идеясын ачу | 10.10 |
| 7 | Р.Батулла “Әйлән-бәйлән уены” | Әкиятнең эчтәлеген төшендерү, уен видео буенча фикер алышу | 17.10 |
| 8 | Р. Батулла. “Аю Әппәс”. | Әкиятне сөйләргә өйрәтүдә уеннар | 24.10 |
| 9 | Ш.Галиев “Танышмак өчен табышмак”<br>БСҮ “Яраткан кошларыбыз һәм хайваннарыбыз” | Табышмак ңавабын табарга өйрәтү күнегүләре | 7.11 |
| 10 | Г. Тукай. “Гали белән кәҗә” | Шигырьнең сәнгатьлелегенә игътибар итү.ярыш оештыру | 14 |
| 11 | Г. Тукай  “Бала белән күбәләк”<br>“Карлыгач” шигыре. | Диалогик  сөйләм рәсем буенча оештыра белү | 21 |
| 12 | Р. Вәлиева.“Күбәләк һәм кырмыска”, “Күбәләк белән керпе”. | әкият персонҗалары булып уйнау төркемнәргә оешу | 28.11 |
| 13 | Х. Халиков. “Укытучыларым”<br>З.Мансур “Кырмыска” шигыре. | Укытучылар булып уйнау | 5.12 |
| 14 | М. Әгъләмов. “Бүләк”.<br>Г.Сабитов “Балага-бүләк” | Бүләк төшенчәсен бирү бүләк ясау төркеминәрдә эш | 12.12 |
| 15 | Такмаклар. | Такмаклар белән танышу җырлау. | 19.12 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 16 | Тел шомарткычлар. | Халык авыз иҗаты төшенчәсен бирү схема ясау | 9.01 |
| 17 | “Шүрәле” әкияте белән танышу. | Мултфилм карау фикер алышу | 16 |
| 18 | Кола ат. (Татар халык әкияте). | Текст буенча сорауларга җавап бирү, нәтиҗә ясаукитап белән эш. | 23 |
| 19 | Алдавыч әкият. “Мактанчык каз” әкияте. | Әкият эчтәлеге  буенча төркемнәрдә фикер алышу | 30.01 |
| 20 | Мәзәкләр. | Кызыклы сөйләмне, юморны аңлауга күнегүләр | 6.02 |
| 21 | Табышмаклар. | Табышмаклар белән уеннар | 20 |
| 22 | Санамышлар.<br>Р.Миңнуллин “Саный беләм” | Санамышлар турында беренче мәгълүмат бирү. | 27.02 |
| 23 | Г. Хәсәнов. “Ел язга аяк атлады” | Ел фасыллары белән таныштыруны дәвам итү картиналар чагыштыру | 6.03 |
| 24 | Г. Галиев “Кояш”.<br>С.Сөләйманова “Кем уяткан Ләйләне” шигыре. | Текст буенча сорауларга җавап бирә белү, анализлау. | 13.03 |
| 25 | Ш. Галиев. “Яз”, Н. Каштанов “Болыт”. | Шигырьнең эчтәлеген аңлау.анализлау | 3.04 |
| 26 | Ш. Галиев. “Яз”, Н. Каштанов “Болыт”. | Язгы үзгәрешләр белән таныштыруга рәсемнәр | 10 |
| 27. | С.Муллагалиев “Яз иде”<br>Ә.Бикчәнтәева “Җил сөйләшә беләме?” | Әдәби текстны дөрес, сәнгатьле уку | 17 |
| 28. | БСҮ. Бүген Тукай туган көн.<br>Г.Тукай “Яз” | Г. Тукай турында мәгълүмат. Презент. | 24.04 |
| 29. | Дәрдемәнд.” Гали”<br>Җ.Тәрҗеманов “Биш чия”. | Сәнгатле укуга конкурс | 1.05 |
| 30. | И. Туктар. “Өлгер”<br>Л. Лерон. “Супермалай”. | Бер-берәңә ярдәм итү, матур сүзләр әйтә белү күнегүләре | 8.05 |
| 31. | .Ф. Яруллин “Хикмәтле сүз”.<br>Р.Вәлиева “.Дуслык” | Авторлар турында | 15.05 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | мәглүмат җыю | |
| 32 | Г. Зәйнашева. “Бер атнада ничә көн?”<br>Ш.Галиев “Светофорның өч күзе” | Шигырьнең эчтәлеген аңлауга сораулар төзү. | 22.05 |
| 33 | БСҮ. Безнең гаилә<br>Т.Әйди “Дачада”.Йомгаклау дәресе. | Бәйләнешле сөйләм телен үстерүгә уеннар. | 22.05 |
| | | | |

Пронумеровано

и скреплено печатью ___восемь___ листов

Учитель ___________ И.Х.Замалиев